**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**УРЫССУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**23 май 2015 ел** **Иске Урыссу ав.** **№10**

Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең
2014 елның 21 ноябрендәге «Җир салымы турында»гы 23 санлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының II өлешенең 31 бүлегенең 387 маддәсенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Советы **карар бирә:**

1. Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең 2014 елның 21 ноябрендәге «Җир салымы турында»гы 23 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

"Салым ташламалары" турындагы 3 маддәдә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә игълан итәргә:

«1. Кадастр бәясеннән ташламалы салым ставкасын:

1) Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирле бюджеттан финанслана торган казна, автоном, бюджет учреждениеләре, идарә органнары тарафыннан билгеләнгән һәм салым салу объектлары дип танылган җир кишәрлекләренә карата 0,2%;

2) 1-3 категорияле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен бирелә торган җир участокларына карата 0,05%.

2. Әлеге карарны:

2.1. административ бинаның мәгълүмати стендында һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга;

2.2. Россия Федерациясе Салым кодексының I өлешендәге 5 маддәсенең 3 һәм 4 пунктларына ярашлы рәвештә, 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Урыссу авыл җирлеге башлыгы Р.С. Мөхәмәтҗанова